**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 26 декабрь № 997

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Даими рәвештә кеше каравына (ярдәменә, күзәтүенә) мохтаҗ булган инвалид балаларга өстәмә айлык акчалата түләү турында» 2012 ел, 7 март, 188 нче карары белән расланган Даими рәвештә кеше каравына (ярдәменә, күзәтүенә) мохтаҗ булган 18 яшькә кадәрге инвалид балаларга өстәмә айлык акчалата түләү бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Даими рәвештә кеше каравына (ярдәменә, күзәтүенә) мохтаҗ булган инвалид балаларга өстәмә айлык акчалата түләү турында» 2012 ел, 7 март, 188 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 29 май, 429 нчы, 2013 ел, 19 гыйнвар, 20 нче, 2013 ел, 12 март, 157 нче, 2013 ел, 31 октябрь, 828 нче, 2015 ел, 29 июль, 550 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Даими рәвештә кеше каравына (ярдәменә, күзәтүенә) мохтаҗ булган 18 яшькә кадәрге инвалид балаларга өстәмә айлык акчалата түләү бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 нче пунктның беренче абзацында «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе» сүзләрен «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга;

7 нче пунктның өченче абзацында, 10 нчы пунктта «индивидуаль тернәкләндерү программасы» сүзләрен «индивидуаль тернәкләндерү яки абилитация программасы» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2016\997.doc